ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.10.2022 с.Старое Дрожжаное № 527

2022 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2022 елның 4 кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2022 елның 20 сентябрендәге 773/пр номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Авыл җирлегендә яшәүче яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең яшәү шартларын яхшырту максатларында 2014-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 2022 елның IV кварталына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 29 000 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы Р.Р. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов